РАСЛЫЙМ
«Тайсуган авылы балалар
бакчасы мөдире
________________В.Х.Абдуллина

# Икенче кечкенәләр һәм уртанчылар төркемендә

# 2021-2022 елга календарь план

Тәрбиячеләр: Миркасимова Р.Р.
Абдрашитова А.И.

1 сентябрь Сишәмбе

| Көндәлек режим | Күпкырлы Белем бирү эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |
| **Иртән** | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Иртәнге гимнаста<br>Тәме буенча таны!<br>*Максат:* Балаларны тәме буенча җиләк-җимешләрне сизеп, аның нәрсә һәм тәме нинди булуын әйтә белергә өйрәтү. Сүзлекне сыйфатлар белән баету<br>Дид\уен: “Бәйрәмгә өстәл әзерлибез!”<br>Максат: Уйлау-фикерләү сәләтен үстерү, зәвык тәрбияләү. Төсләрне кирәгенчә сайлап алырга, аларга туры килүчеләрен сайларга өйрәтү. | калакларны дөрес итеп тотарга,<br>ашаганда урындыкка дөрес итеп утырырга кунектерү.<br>Дид\уен:”Төймә җыябыз.”<br>Максат:Геометрик фигураларны ныгыту.Төсләрне ныгыту.Бармак моторикасын ныгыту.Фикерләү сәләтен үстерү.<br>Материал:түгәрәк төсле төймәләр,шнурлар. | Балаларны бүлмәдәге тәртипсезлекне күрә белергә өйрштү.бүлмәне һәм уенчыкларны тәртиптә тотарга гадәтләндерү. | Сюжетлы-рольле уен - ситуация<br>“ Кем шофер”- балалар машиналар белән уйныйлар;<br>тэрбияче сораулар бирэ: Мина кибеткэ барырга кирэк. Кем алып барыр икэн?... | |
| **Белем бирү эшчәнлеге** | **Әвәләү. Тема: «Көзге уңыш» (җиләк-җимешләр).**<br>**Максат:** Сурәтне тулыландырганда, әвәләп ясауның таныш алымнарын кулланырга өйрәтү. Балаларның төрле зурлыктагы түгәрәк предметларны әвәләп ясау күнекмәләрен ныгыту.<br>Балаларны туган як үсемлекләре белән таныштыруны дәвам итү.<br><br>**Физкультура**<br>**Задачи:** Упражнять детей в ходьбе и беге колонной по одному; учить сохранять устойчивое равновесие на уменьшенной площади опоры; упражнять в энергичном отталкивании двумя ногами от пола (земли) и мягком приземлении при | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | подпрыгивании. | | | | | |
| **Прогулка** | Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш. | Саф һавада йөрү<br>Кояшны күзәтү, балаларда күзәтүчәнлек тәрбияләү, гомуми нәтиҗә ясарга ойрәту (кояш актырта, җылы) | Индивидуаль эш: ике аяк белән бер урында сикерү<br>. | Хәрәкәтле уен: “Чыпчыклар һәм автомобиль”, “Без-шоферлар”.<br>Максат:<br>– төсләрне аерып хәрәкәтләнергә өйрәнү;<br>– пространствода ориентлаша белү;<br>– уен оештыруда мөстәкыйльлек тәрбияләү | Аз хәрәкәтле уеннар: «Машина килә», «Куык», «Тигез юл буйлап», «Кошчыклар»<br>Уенчыкларны җыеп куярга өйрәтү. | |
| **Кич** | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Йокыдан соң гимнастика<br>Массажлы коврикларда йөрү.<br>Сюжетлы-рольле уен”Шифаханә”-балаларның табиб һөнәре турындагы белемнәрен баету.Авыруга ярдәм күрсәтергә өйрәтү,шәфкатьлелек тәрбияләү.<br>“Куян кызы”мультфильмын карау.Эчтәлеге буенча әңгәмә үткәрү. | “Бу әйберләр кемгә кирәк?”дид\уен-балаларны профессияләр белән таныштыру.<br>Дид\уен:”Нәрсә үзгәрде ?”<br>Максат: Геометрик фигураларны таный белү.Балаларның логик фикерләүне, уйлау сәләтен үстерү.<br>Материал:2 түгәрәк һәм 2 квадрат. | Мөстәкыйль киергә,чишенергә өрәтүне дәвам итү.Төймәләрне чишү,төймәләү,ботинкаларның бауларын чишү,бәйләү күнекмәләрен булдыру.<br>Киемнәрен элеп яки төреп куярга гадәтләндерү. | Уенчык аю,курчаклар ,бинт,табиб киемнәре булдыру. | “Телевидение һәм кечкенә балалар психикасы”темасына һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |

1 сентябрь Чәршәмбе

| Көндәлек режим | Күпкырлы белем бирү эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |
| **Иртән** | социаль-коммуникатив үсеш танып белү үсеше сөйләм үстерү физик үсеш. | "Конструктор" Балаларны гади пластмас конструктор белән таныштыру. Тәрбияче белән берлектә конструктордан өйләр, машиналар төзергә өйрәтү. Үзләре ясаган корылмалар белән уен оештыру. Балаларның фантазиясен баету. Игътибарлылык тәрбияләү. | төсләрне ныгыту өстендә эш . (Дид.уен: "Үз өен тап".) Кайсы фигура артык ? Максат:Геометрик фигураларны истә калдыру.Фигураларның аерымлык билгеләрен табарга өйрәтү,ныгыту. Материал:кызыл түгәрәк,зәңгәр түгәрәк,яшел квадрат. | -уйнаганнан соң уенчыкларны урыннарына алып куярга кунектерү | Табигать почмагында эш. -балалар белән гөлләргә су сибү,төпләрен йомшарту. | "Бала үсешенә ата-аналар куйган таләпләрнең тәэсире" күчмә-папка төзү |
| **Белем бирү эшчәнлеге** | **ФЭМП**<br>**Тема:** Бер -күп, күплекне чагыштыру һәм алар арасындагы бәйләнеш. Зур, кечкенә. Түгәрәк. Е.В.Колесникова. - 15 б.<br>**Максат:**Предметлар микъдарын чагыштырырга, бер һәм күп төшенчәсен аерырга өйрәтү. Дөрес алым кулланып, 2 гә кадәр санау күнекмәсен үстерү.<br>**Музыка.** Музыка житэкчесе планы буенча | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Прогулка** | Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш. | Светофорны күзәтү.<br>Урамнарны күзәтеп,<br>Узганнарны кисәтеп,<br>Чатта тора светофор,<br>Сакта тора светофор.<br>Әйтеп тора өч сүзен:<br>-Кузгалма, ди кызыл күз!<br>-Сабыр ит, ди сары күз,<br>-Ярый, дия яшел күз! | Индивидуаль эш<br>Уен: “Минем янга йөгерегез”<br>Балаларны сигнал буенча бер – берсенә бәрелмичә йөгерергә өйрәтү. | Хәрәкәтле уен<br>Уен “ Поезд” балаларны бер берсе артыннан калмыйча тотынып йөрергә өйрәтү.<br>Уен “Кечкенә тупларны кэрзингэ ату”- горизонталь цельга атуны ныгыту, куз улчэмен устеру. | Хезмәт: сынган агач ботакларын җыю.<br>Алып чыккан уенчыклар б-н уеннар оештыру. | |
| Кич | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Йокыдан соң гимнастика<br>Өстәл уеннары<br>Лото, пазлы, мозаика, лего<br>Төзелеш материалларыннан юллар төзеп, машиналар белэн уенннар оештыру | Дид.уен:<br>“Таны һәм әйт “<br>-берничә кисәктән торган рәсемне дөрес җыеп ,кайсы әкияттән икәнен әйтеп бирә белергә өйрәтү.<br>Дид\уен:”Нинди фигура.”<br>Максат:Геометрик фигураларның исемен ныгыту.Логик фикерләүне үстерү<br>Материал:төрле төстәге өчпочмак.квадрат, түгәрәк. | Уен вакытында уенчыкларын бер-берсеннән тупас рәвештә тартып алмаска,төзегән әйберне җимермәскә өйрәтү. | Төрле машиналар,конструкторлар. | |

2 сентябрь  Пәнҗешәмбе

| Көндәлек режим | Күпкырлы белем бирү эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |
| Иртән | Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш. | Иртәнге гимнастика<br>"Күңелле лото"<br>Максат:  Сүзлек байлыгын арттыру, игътибарлылыкны, хәтерне, кузаллауны үстерү,мөстәкыйльлек тәрбияләү.<br>Әйберләрне үзләренә генә хас булган билгеләре буенча  төркемләү. | Дид/уен:<br>«Үз төсеңне тап», «Үз өеңне тап».<br>»предметларны төсе һәм зурлыгы буенча аера белергә өйрәтү. | КГК- балаларны юыныр алдыннан киемнәренең җиңнәрен күтәреп куярга, туалетка кергәннән соң кулларны юарга гадәтләндерү. | “Төсле кыстыргычлар”Балаларның бармаклар эшчәнлеген ныгыту.<br>Кызыл, сары, яшел, зәңгәр тйсләрне өйрәтү.<br>Балаларның игътибарын, хәтерен үстерү. | |
| | **Рәсем«Әй ямьле җәй!»**<br>•Балаларны традицион булмаган рәсем ясау техникасына (бармаклар белән) өйрәтүне дәвам итү, җәй фасылы күре-нешләрен белдергән предметларны (кояш, күбәләкләр, агачлар, җиләкләр) ясаганда, тапларны ритмик рәвештә төшерергә өйрәтүне дәвам итү.<br>•Җәйге ялдан туган хис-тойгылар аша туган якка уңай мөнәсәбәт бул¬дыру. Балаларны Б. Рәхмәтнең «Иң күңелле чак» шигыре белән таныштыру<br>**Физкультура** | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Упражнять детей в ходьбе и беге колонной по одному; учить сохранять устойчивое равновесие на уменьшенной площади опоры; упражнять в энергичном отталкивании двумя ногами от пола (земли) и мягком приземлении при подпрыгивании | | | | |
| **Прогулка** | Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш. | *Җилне күзәтү.*<br>Максат:<br>- һава торышының үзгәрүе турындагы күзаллауларны ныгытуны дәвам итү;<br>– җил турындагы төшенчәне формалаштыру<br>Җилле көнне болытларга , җилдә селкенгән агач ботакларына игътибар итү.Җил агач ботакларын сындыра. | Индивидуаль эш**:**<br>**“**Флажокка кадәр йөгереп бар”.<br>*Максат:* йөгерү тизлеген арттыру. | Хәрәкәтле уеннар:<br>“ Чыпчыклар һәм песи”- балаларда җитезлек тәрбияләү. | Хезмәт: агач ботакларын жыю.<br>Алып чыккан уенчыклар белән мөстәкыйль уеннар.<br>Максат: хезмәт күнекмәләре булдыру. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Кич** | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Йокыдан соң гимнастика<br>Әкият илендә.<br>Максат:<br>Сүзлек байлыгын арттыру, игътибарлылыкны, иҗади фикерләүне үстерү;<br>Таныш булган экиятләрне искә төшерү, алар белән диалог төзеп сөйләшү. | индив эш: уенчыклар карау, алар турында сойләү,сөйләм телен үстерү.<br>Дид\уен:"Кайсы фигура юкка чыкты ?<br>Максат:Геометрик фигураларның исемен ныгыту.Фикерләү сәләтен үстерү.<br><br>Материал:түгәрәк,квадрат һәм өчпочмак ,салфетка. | Ихтыяр көче, сабырлык, кыюлык, уен кагыйдәләрен үтәү сыйфатлары тәрбияләү. | Тозелеш материаллары белән уеннар-корылмаларны уенда файдаланырга өйрәтү, аларның исмнэрен ныгыту;<br>уеннан соң пөхтәләп җыеп куярга гадәтләндерү | Әти-әниләрне төркемдәге үзгәрешләр, яңалыклар белән даими таныштырып тору. |

3 сентябрь Җомга

| Көндәлек режим | Күпкырлы белем бирү эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Иртән** | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Иртәнге гимнастика<br>Шырпы - уенчык түгел.-<br>балаларга шырпы белән уйнарга ярамавын һәм бу уенның нәтиҗәләрен аңлатуны дәвам итү. Янгын сүндерү чаралары һәм янгын сәбәпләре турында белемнәрне формалаштыру.<br>Материал: киселгән карточка - рәсемнәр, маскалар, "Путаница" ("Буталчык") әкиятенә иллюстрацияләр, уенчык утсүндергечләр | уйнаганнан соң уенчыкларны урыннарына алып куярга кунектерү<br>Бытый – бытый ботка пешә,<br>Аңа бер тычкан төшә.<br>Аны алам дигәндә<br>Бер бармагы пешә.<br>Әбигә кашык,<br>Бабайга кашык,<br>Әтигә кашык,<br>Әнигә кашык,<br>Куянга кашык. | Ирекле уеннар-балаларны дус, тату уйнарга; уеннар өчен үз теләкләре буенча уенчыклар сайлап алырга өйрәтү. | Төркем бүлмәсендә, мәйданчыкта тәртип һәм чисталык сакларга өйрәтү | Әти-әниләрне төркемдәге үзгәрешләр , яңалыклар белән даими таныштырып тору |
| **Белем бирү эшчәнлеге** | **Сөйләм теле үстерү БЕЗНЕҢ УЕНЧЫКЛАР**<br>1) балаларда предметларны тасвирлау, вак моториканы камилләштерү, исем, сыйфат кулланып гади җөмләләр төзергә өйрәтү, предметлар атамасы, аларның өлешләрен атау, нинди материалдан ясалуы турында сөйләү хисабына сөйләмнәрен активлаштыру, “ш” авазын ныгыту;<br>2)балаларның кызыксынучанлыгын, игътибарын, хәтерен, фикерләвен үстерү;<br>3) балаларда уенчыкларга карата сакчыл караш, үзара дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү<br>**Матур әдәбият белән таныштыру Э.Мөэминованың “Үз телендә сөйләшә" шиг уку**<br>1) балаларны Э. Мөэминованың «Үз телендә сөйләшә» дигән шигыре белән таныштыру; аерым сүзләрне тәрбияче артыннан кабатлап, сөйләмдә активлаштыру;<br>2) аңга алуларын, игътибарын, фикерләүләрен үстерү;<br>3) туган телгә мәхәббәт һәм аны өйрәнү теләге тәрбияләү.<br>**Физкультура (һавада)** | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Упражнять детей в ходьбе и беге колонной по одному; учить сохранять устойчивое равновесие на уменьшенной площади опоры; упражнять в энергичном отталкивании двумя ногами от пола (земли) и мягком приземлении при подпрыгивании | | | | | |
| **Прогулка** | Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш. | Саф һавада йөрү<br>Урамда йөрүче транспортны күзәту-транспорт төрләренен исемнәрен ныгыту, кузәтучәнлек тәрбияләү | Уен.”Төсле автобуслар”.Төсләрне, формаларны аера һәм чагыштыра белергә өйрәтү, автобуста үз – үзеңне тота белү күнекмәләрен үстерү. | Хәрәкәтле уен 106 Р. К. Шәехова («Чыпчыклар һәм автомобиль», «Поезд» һ. б.) кагыйдәләрен үтәргә өйрәтү. | Хезмәт : Юлларны себерү-ярдәм итү телэге уяту, хезмәткә унай караш тэрбиялэү,балаларда күмәк эштә катнашу теләге уяту.<br>Урамга алып чыккан уенчыклар белән балаларның мөстәкыйль уеннары. | |
| Кич | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Йокыдан соң гимнастика<br>Массажлы коврикларда йөрү.<br>"Кайсы артык"<br>Максат:<br>Сүзлек байлыгын арттыру, игътибарлылыкны, иҗади фикерләүне, хәтерне, кузаллауны үстерү,мөстәкыйльлек тәрбияләү.<br>Әйберләрне үзләренә генә хас булган билгеләре буенча төркемләү. | уенчыклар рәсемнәрен карау,аларны дөрес әйтергә өйрәтү.<br>Дид\уен:”Кайсы шарф озын ?<br>Максат:Балаларның озын кыска төшенчәсен,төсләрне ныгытырга өйрәтү.Уйлау сәләтен үстерү.<br>Материал:озын кызыл һәм кыска сары шарфлар,уенчык аю һәм куян. | Коллективизм хисе тәрбияләү. | .«Гаиләм» дип исемләнгән бармак уенының сүзләрен өйрәтү, уенны уйнату.<br>. | *«Балалар бакчасында режим моментлары һәм көндәлек режимны оештыру*» дигән консультация уздыру. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|

6 сентябрь  Дүшәмбе

| Көндәлек режим | Күпкырлы белем бирү эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |
| Иртән | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Иртәнге гимнастика "Төсле поезд"<br>Максат:<br>1.Балаларның сөйләм телен үстерү, диалог төзеп сөйләү күнекмәләрен ныгыту.<br>2.Сүзлек байлыгын арттыру, игътибарлылыкны, иҗади фикерләүне, хәтерне үстерү.<br>. | Индив эш: “озын –кыска; “Озынрак, кыскарак” төшенчәләрен кулланып предметларның озынлыгын чагыштырырга өйрәтү. | Узара бүлешеп дус уйнауларына ирешү. | Төрле транспорт төрләре рәсемнәре,вак мишиналар.<br> | Балалар бакчасының шәфкать туташы киңәшләрен ата-аналар почмагына урнаштыру |
| Белем бирү эшчәнлеге | **Әйләнә тирә дөнья**<br>Тема:БЕЗНЕҢ ЯРАТКАН АПАБЫЗ<br>1) тәрбияче ярдәмчесе һөнәре турында балаларның күзаллауларын формалаштыруны, таныш һөнәрләр атамасын ныгытуны дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, сүз байлыгын үстерү;<br>3) балаларда зурлар хезмәтенә карата хөрмәт тәрбияләү.<br>**Сөйләм теле үстерү Куян үстергән кишер һәм помидор**<br>1) балаларга табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турында мәгълүмат бирү, яшелчәләр (кишер, помидор) турындагы белемнәрен ныгыту; | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2) балаларның яшелчәләрне (кишер, помидор) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белүләренә ирешү; игътибарын, аңга алуларын, диалогик сөйләмен, сенсорик күнекмәләрен үстерү;<br>3) балаларда сорауларга җавап бирү теләге уяту; табигатькә уңай караш тәрбияләү<br>**Музыка.** Музыка житэкчесе планы буенча | | | | | |
| Прогулка | Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш. | Саф һавада йөру<br>Яңгыр яуганын күзәтү-тирә-юньдәге булган матурлыкны күрә белүне формалаштыру, суның сыйфатлары белән таныштыру.<br>“ Яңгыр...”-шигыр уку. | **Индивидуаль эш.**<br>“Кем тизрәк йөгереп барып җитә?”,”Ташларга басып”.<br>*Максат:* йөгерү күнегүләрен кабатлау, ташларга басып йөргәндә тотрыклылык (тигезлек) саклау, сигнал буенча тиз хәрәкәт итү | Уен: “Минем янга йөгерегез”<br>Балаларны сигнал буенча бер – берсенә бәрелмичә йөгерергә өйрәтү. | Участокны тәртипкә китерү.Балаларда күмәк эшкә катнашу теләге тудыру. | |
| Кич | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Йокыдан соң гимнастика.<br>“Шифаханә”<br>Уенның сюжеты буенча төркемнәргә бүлешеп, уен ахырына кире бердәм берләшү күнекмәләрен үстерү. Уенда тирә-юньдәге чынбарлыкны чагылдырырга гадәтләндерү | Уен: “Үз төсеңне тап”<br>Предмртларны төсләре буенча чагыштыру һәм группалаштыру,балаларның сөйләмен үстерү.<br>Кызыл,яшел,сары түгәрәкләр, предметлар.<br>(Бер төркем балалар белән) | Балаларның сөйләм телләрен үстерү, сүзлек запасын баету, игътибарларын, хәтерләрен ныгыту йөзеннән тел шомарткычлар өйрәнү. | .Туфайлованың “Шофер булам”, Н.Измайлованың “Машина ала белмисез” шигырьләрен уку.<br>Балаларда шофер хезмәтенә кызыксыну, өлкәннәр сыман булу теләге уяту.<br> | Әти-әниләр белән әңгәмә. |

7 сентябрь   Сишәмбе

| Көндәлек режим | Күпкырлы белем бирү эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Иртән** | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Иртәнге гимнастика<br>Дид\уен:Сыйфатын билгелә!<br>Максат: Балаларны теге яки бу әйбернең билгеләрен дөрес атарга өйрәтү. Сүзлекне ачыклау, активлаштыру, баету. Күзәтүчәнлекне үстерү. | Уен.”Төсле Автобуслар”<br>Төсләрне, формаларны аера һәм чагыштыра белергә өйрәтү, автобуста үз – үзеңне тота белү күнекмәләрен үстерү.<br>Кызыл,сары, яшел төстәге автобуслар.<br> | Уеннарның төрләренә карата кызыксынучанлыклы, мөстәкыйльлекне үстерү. | Уен почмакларында балаларның мөстәкыйль уеннары.<br>Хезмәт йөкләмәсе: уенчыклар җыю- балаларда хезмәт күнекмәләре формалаштыру, мөстәкыйллек тәрбияләү, иптәшләренә үзара ярдәм итешү. | “Әти, әни һәм мин – без тату гаилә” – рәсемнәр конкурсы |
| **Белем бирү эшчәнлеге** | **Кисеп ябештерү** «Чәчәк түтәлен (клумбаны) киртәләү».<br>• Балаларны кайчы белән эшләргә, тар кәгазь тасмасын тигез кисәкләргә кискәләп бүләргә өйрәтү.<br>• Җилем һәм пумала белән эшләү күнекмәләрен, урнаштыру һәм ябыштыру алымнарын ныгыту.<br>Балаларда үз-үзеңне тәртипле тоту теләге уяту, олылар хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.<br>**Физкультура**<br>Учить детей энергично отталкиваться от пола и приземляться на полусогнутые ноги при подпрыгивании вверх, доставая до предмета; упражнять в прокатывании мяча. | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Прогулка** | Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш. | Саф һавада йөрү<br>Кугәрченне күзәтү.<br>Максат: күгәрчен белән таныштыру , тышкы кыяфәтенең үзенчәлекләре, гадәтләре белән.<br>Күзәтүнең барышы:<br>Тәрбияче сораулар бирә.Табышмак әйтә.<br>Бу нинди кош?<br>Нинди төстә?<br>Күгәрченнең тормышында кыш көне нинди үзгәрешләр була?<br>нәрсә белән туклана?<br>Кешеләр алар турында ничек кайгырталар? | Индивидуаль эш:<br>«Кояш һәм яңгыр» дигән сүзле-хәрәкәтле уенның сүзләрен, хәрәкәтләрен өйрәтү, уенны уйнату. | Хәрәкәтле уен<br>“ Чыпчыклар хэм автомобиль”-<br>*Максат:* шуышып чыгу, бер-берeңә бәрелмичә йөгерү, тәрбияче сигналы буенча тиз хәрәкәт итү. | Хезмәт:<br>Юлларны, өй эчләрен чистарту, себерү<br>Максат:себерке белән эшләү күнекмәләрен ныгыту,<br>хезмәттә катнашу теләге тәрбияләү, эш нәтиҗәләренә карата сак караш тәрбияләү. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Кич** | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>физик үсеш | Йокыдан соң гимнастика<br>Массажлы коврикларда йөрү. | Дид\уен:”Үз өеңне тап.”<br><br>Максат:Балаларның геометрик фигураларны истә калдырырга.Пространствода дөрес ориентлашырга өйрәтү.<br>Материал:3 кыршау һәм һәр балага җитәрлек итеп квадрат ,өчпочмак,түгәрәк.<br>Ислам,Ренал. | Табигать почмагындагы булмә гөлләрен карау, аларга су сибуне кузәтү – балаларда усемлекләргә карата кайгыртучанлык хисе уяту | Мозаикалар,вак төзелеш материаллары,пазлылар. | |

8 сентябрь  Чәршәмбе

| Көндәлек режим | Күпкырлы белем бирү эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Иртән** | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>физик үсеш. | Иртәнге гимнастика.<br>Дид\уен “Поезд”<br>Бүлмәдә ориентлашу, бер-бер артлы тезелеп йөрү.<br>Тукылдый да тукылдый<br>Алга барабыз.<br>Еракка бик еракка<br>Илтә паровоз.<br>Дид\уен:”Серле таякчыклар.”<br>Максат:Таякчыклардан квад-рат,өчпочмак төзергә өйрәтү.Уйлау сәләтен үстерү.<br>Материал: таякчыклар 4 кызыл һәм 3 сары. | Дид\уен:”Кемнең сукмагы озынрак ?”<br>Максат:Озын һәм кыска төшенчәсен ныгыту.Берсе өстенә икенчесен куеп карау алымы белән тикшерү.Төсләрне ныгыту.<br>Материал:Бүре һәм Кызыл Калфак,озын кызыл һәм соры кыска тасмалар. | Пластилинны өзеп алып, учта түгәрәк формалар әвәләргә өйрәтү, пластилин белән эшләү күнекмәләрен үстерү. | Тозелеш материаллары белән уеннар оештыру-конструкциялэу осталыкларын устеру.<br>Хезмәт йөкләмәсе: уенчыклар җыю-балаларда хезмәт күнекмәләре формалаштыру, мөстәкыйллек тәрбияләү, иптәшләренә үзара ярдәм итешу | Консультация әти – әнилэр өчен “Баланың буш вакытын ничек үткәрергә” |
| **Белем бирү эшчәнлеге** | **ФЭМП**<br><br>**Тема:3 һәм 4 саннарын чагыштыру үрнәк буенча санау. Табышмаклар. Күз, сул, уң.** Е.В. Колесникова. - 18 б.<br><br>Максат: Дөрес алым кулланып, предметларны 4 кә кадәр санарга өйрәтү. Үрнәк буенча санау, 2 төркемдәге предметлар арасына тигезлек куарга өйрәтү. Күз турында булган белемнәрен ныгыту.<br><br>**Музыка:** музыка житэкчесе планы буенча | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Прогулка** | Танып белү<br>Сөйләм<br>теле үсеше.<br>Физик үсеш. | САф һавада йөрү<br>Каргаларны күзәтү- каргаларның гәүдә төзелешләренең үзенчәлекләренә игътибар итү.<br>Балаларың күзәтүчәнлекләрен,кызыксынучанлыкларын үстерү;<br>(Карга үзе соры, томшыгы, башы,канатлары, койрыгы кара; ашамлыкны томшыгы белән алып агач ботагына кунып ашый) | **Индивидуаль эш.**<br>“Кем тизрәк йөгереп барып житә?”,”Ташларга басып”.<br>*Максат:* йөгерү күнегүләрен кабатлау, ташларга басып йөргәндә тотрыклылык (тигезлек) саклау, сигнал буенча тиз хәрәкәт итү | Хәрәкәтле уен:<br>«Үз өйеңне тап».<br>Бур-р: баларны бер-берсенә бәрелмичә йөгерә белүләрен ,<br>сигнал буенча хәрәкәтләнә белүне ныгыту. | Хезмәт:<br>Комнан корылмалар ясау.<br>Комлыкны йомшарту, чистарту.<br>Цель: Көрәк белән эшләү күнекмәләрен ныгыту | |
| Кич | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү<br>үсеше сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Йокыдан соң гимнастика<br>Транспорт төрләре сүрәтләнгән рәсемнәр карау.<br>Балаларны трапспорт төрләрен аера белергә өйрәтү. | 2–3 жөмләдән торган хикәяләр төзергә өйрәтү. Жөмләдәге сүзләрне дөрес бәйләр өчен, кушымчаларны дөрес файдала- нырга өйрәтү. | Каләмнәрне дөрес тотарга, төсле каләмнәр белән рәсем ясарга өйрәтү; рәсем ясарга теләк тәрбияләү,үстерү | Төрле транспорт рәсемнәре,карандаш һәм фломастерлар.<br> | |

9 сентябрь Пәнҗешәмбе

| Көндәлек режим | Күпкырлы белем бирү эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |
| | Танып белү<br>Сөйләм<br>теле үсеше.<br>Физик үсеш. | Дид\уен”Дөрес итеп әйт” «Яшелчә», «Җиләк җимеш» :предметларны кулланышы ,төсе ,формасы ,материалы буенча чагыштыру һәм төркемнәргә аера өйрәтү. | “Шундый ук предметны тап”дид.уены. балаларны үз фикерләрен грамматик яктан дөрес итеп ике-өч сүздән торган гади җөмләләр белән белдерергә өйрәтү, гомумиләштерү күнекмәләрен булдыру | гигиена күнекмәләрен тәрбияләү. | Машиналар, коляскалар б/н уеннар- Уеннар вакытында балаларнын уз ара аралашуларына игътибар иту, балаларнын торкемлэшулэрен хуплау | Ата-аналар өчен педагог-психолог, шәфкать туташының киңәшләре тупланган төрле папкалар булдыру. |
| | **Рәсем«Бакча агачлары һәм куак-лары».**<br>•Агач һәм куакның төп өлешләрен, пропорцияләрен чагыштырырга һәм рәсемгә төшерергә өйрәтү.<br>•Кәүсәне буяганда, сурәтне төсле карандашлар яки фломастерлар белән матурлап ясап бетерү.<br>•Балаларны туган як үсемлекләре белән таныштыруны дәвам итү.<br>**Физкультура**<br>Учить детей энергично отталкиваться от пола и приземляться на полусогнутые ноги при подпрыгивании вверх, доставая до предмета; упражнять в прокатывании мяча. | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Прогулка** | Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш. | саф һавада йөрү агачларны, куакларны күзәтү- агачлар турында баларның белемнәрен ныгыту, аларга карата сакчыл караш тәрбияләү ( кыш көне аларның ботаклары тиз сынучан, шуның өчен аларны сакларга кирәк, сындырмаска ,көрәк белән ботакларына сукмаска) | Индивидуаль эш: | Уен: “Светофор”<br>Сигналлар ярдәмендә хәрәкәт итәргә өйрәтү.<br>Светофор макеты кызыл,сары, яшел төстәге түгәрәкләр.- Балаларны уенда актив катнашуларына теләк белдерергә ирешү.<br> | Хезмәт<br>Уенчыкларны себеру, юу- балаларда өлкәннәрнең хезмәт эшчэнлегенә көчләреннэн килгәнчә ярдэм итәсе килү теләге тудыру. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Кич** | социаль-коммуникатив үсеш танып белү үсеше сөйләм үстерү сәнгати үсеш физик үсеш. | “Чуар тавык”әкиятен уку. Балаларны халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыруны дәвам итү,әкиятләрне тыңлау теләге тудыру, чуар, күкәй,алтын, гади, тычкан кебек сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын активлаштыру. | Балаларны төрле юнәлештә туры сызыклар (кыска, озын, вертикаль, горизонталь, авыш) сызарга өйрәтү.<br>Дид\уен:”Һава шарлары.”<br><br>Максат:Предметның төсен,зурлыгын дөрес аеру.Уйлау сәләтен үстерү.<br>Материал:кызыл ,сары,яшел,зәңгәр төсле шарлар. | Шапшаклык, җыйнаксызлык кебек сыйфатларга тискәре мөнәсәббәт тәрбияләү | Сюжетлы рольле Уен:»Чәчтараштa .<br>Рольләрне дөрес бүлешеп дус һәм тату уйнауларына ирешү.<br>-уйнаганнан соң Һәрбер уенчыкны үз урынына тәртип белән алып куярга өйрәтү. | |

10 сентябрь Җомга

| Көндәлек режим | Күпкырлы белем бирү эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Иртән** | социаль-коммуникатив үсеш танып белү үсеше сөйләм үстерү сәнгати үсеш физик үсеш. | Иртәнге гимнастика<br>Аю баласына уенчык сайларга булышу.- янгын ягыннан куркынычлы предметлар турында белем формалаштыру, янгын вакытында уз-үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәтү, кайбер ут сүндерү чаралары турында күзаллау тудыру.<br>Материал: 3-4 уенчык, янгын чыгу куркынычы булган әйберләр (шырпы, шәм, утүк, розетка), янгын сүндерү предметлары, янгын темасына иллюстрация. | Дид\уен:"Күңел ле кешеләр."<br><br>Максат:Геометр ик фигураларның исемнәрен һәм аерымлык билгеләрен табарга өйрәтү.Логик фикерләүне үстерү.<br>(Ислам,)<br>Материал:Төрле төстәге ,төрле зурлыктагы геометрик фигуралар (түгәрәк,квадрат ,өчпочмак).<br>(Миләүшә) | Корылма үрнәкләрен анализларга: төп өлешләрен аерырга, зурлыклары, формалары буенча таный белергә өйрәтү, төзелеш детальләре белән таныштыруны дәвам итү, төзелеш материалларына сак караш тәрбияләү (авызга капмаска һ.б.). | Төркем бүлмәсендә, мәйданчыкта тәртип һәм чисталык сакларга өйрәтү | . |
| **Белем бирү эшчәнлеге** | **Матур әдәбият белән таныштыру** "ЯФРАК БӘЙРӘМЕ" ШИГЫРЕН УКУ.<br>1) балаларны көзге табигать матурлыгы белән таныштыру, шигырьнең эчтәлеге буенча җавап биргәндә авторның шигъри юлларын кулланырга өйрәтү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, күзәтүчәнлеген, тәрбияче артыннан сәнгатьле итеп кабатлау осталыгын үстерү;<br>3) балаларда бергә шөгыльләнү, сорауларга җавап бирү теләге уяту, көзге табигать белән соклану тәрбияләү.<br>**Ә.Бикчәнтәеваның "Туп" шигырен яттан өйрәнү**<br>1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү; сорауларга җавап бирүгә күнектерү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, хәтерен, интонацияле сөйләмен үстерү;<br>3) балаларда кечкенәләр турында кайгыртучанлык хисе тәрбияләү; бергә шөгыльләнергә теләк уяту | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | **Физкультура (hавада)**<br>Учить детей энергично отталкиваться от пола и приземляться на полусогнутые ноги при подпрыгивании вверх, доставая до предмета; упражнять в прокатывании мяча. | | | | | |
| **Прогулка** | Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш. | Каен агачын күзәтү<br>Максат:<br>Агачлар турында балаларның белемнәрен киңәйтү;<br>Агачларны саклау теләге тәрбияләү.<br>Участоктагы агачларны карап чыгу, таныш каен агачын табу. Аның нинди кисәкләдән торуын ачыклау ( кәүсә, ботаклар)Башка агачлардан нәрсәсе белән аерылып тора? | Индивидуаль эш:<br>Кар тупларын күрсәтелгән җиргә төбәп ыргыту.<br>Максат: бер кул белән төбәп ыргыту күнегүләрен ныгыту.<br>(Ландыш,Әмир) | Уен “Минем янга йөгерегез”<br>Балаларны сигнал буенча бер-берсенә бәрелмичә йөгерергә өйрәтүне дәвам итү. | Уенчыкларны җыю,участокны тәртипкә китерү. | |
| Кич | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Йокыдан соң гимнастика<br>Массажлы коврикларда йөрү.<br>Сенсор почмагында уеннар<br>-балаларны аерым | «Яңгыр ява» темасына кәгазь битләрендә бармак белән рәсем ясау. | *«Гаиләм»* дип исемләнгән бармак уенының сүзләрен өйрәтү, уенны уйнату. | Курчак театры өчен әсбаплар әзерләү. | *«Балалар бакчасында режим моментлары һәм көндәлек режимны* |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | предметларны бер төркемгә җыеп,шуннан бер предметны аерып алырга,бер һәм күп төшенчәләрен белергә өйрәтү. | | | | *оештыру*» дигән консультация уздыру. |

13 сентябрь Дүшәмбе

| Көндәлек режим | Күпкырлы белем бирү эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |
| Иртән | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Иртәнге гимнастика Уенчык йөк һәм җиңел машиналар карау, әңгәмә үткәрү.<br>Балаларны транспорт төрләрен аера белергә өйрәтүне дәвам итү, сөйләмне үстерү. | Дид\уен:”Бер ,күп.”<br>Максат:Балаларны бер һәм күп төшенчәсен аера белергә.Фикерләү сәләтен үстерү.<br>Материал:1 алма,5 керпе. | урамга чыкканда киенү, аяк киемнәрен узләре киюләренә ирешү | Сюжетлы-рольле уен “Шифаханә”- уен сюжетын арттыру,диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү.Ягымлы сүзләрне сөйләм телендә куллану | Балалар бакчасының шәфкать туташы киңәшләрен ата-аналар почмагына урнаштыру |

<table>
<tr><td>Белем бирү эшчәнлеге</td><td colspan="5">Әйләнә тирә дөнья БАСУГА БАРУ<br>1) балаларның  транспорт (поезд) һәм аның төп билгеләре (төс, материал) белән таныштыруны дәвам итү, яшелчәләр (кишер, чөгендер) турындагы белемнәрне ныгыту;<br>2) яшелчәләрнең тышкы күренеше, тәме, формасы буенча (кишер, чөгендер) аера белү осталыгын, игътибарын, кабул итүләрен, диалоглы сөйләмен, сенсор сәләтләрен үстерү, [у] авазын дөрес әйтүләренә ирешү;<br>3)балаларда табигатькә уңай караш тәрбияләү.<br>Сөйләм теле үстерү“Аю белән Бабай”әкиятен уку<br>1) әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү; үсемлекләр турындагы белемнәрен киңәйтү; сүзлекләрен баету һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен, кулның вак моторикасын үстерү;<br>3) халык авыз иҗаты әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү<br>Музыка: музыка житэкчесе планы буенча</td></tr>
<tr><td>Прогулка</td><td>Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш.</td><td>Экскурсия. Урам белән танышу.Балаларның урам, юл, тротуар, җиңел һәм  йөк машиналары турындагы белемнәрен тулыландыру, юлда үзеңне ничек тотарга кирәклеген ачыклау.<br></td><td>Индивидуаль эш<br>Уен “Алмагач ясадык”<br>Без урамда уйнадык,уйнадык.<br>(Түгәрәк буйлап баралар)<br>Алмагач ясадык, ясадык<br>(Курсэтэлэр)<br>Алмагач миннән биек, бик биек<br>( аяк очларына басып, кулларны өскә күтәрәләр)<br>Алмагач миннән юан, бик юан.<br>( Күрсәтәләр)<br>Алмагач тәбәнәк,</td><td>Уен “Чыпчыклар һәм автомобиль”. Бер-береңә бәрелмичә чәчелеп йөрергә, сигнал буенча хәрәкәт итәргә<br>өйрәтү.</td><td>Хезмәт<br>Юлларны себерү-балаларда өлкәннәрнең хезмәт эшчэнлегенә көчләреннән килгәнчә ярдәм итәсе килү теләге тудыру.</td></tr>
</table>

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | тәбәнәк.<br>(Кулларын алга сузып чүгәлиләр)<br>Китә яздым тәгәрәп, тәгәрәп.<br>(иелгән килеш әйләнеп алалар) | | | |
| Кич | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Йокыдан соң гимнастика З.Туфайлованың “Шофер булам”, Н.Измайлованың “Машина ала белмисез” шигырьләрен уку.Балаларда шофер хезмәтенә кызыксыну, өлкәннәр сыман булу теләге уяту. | “Шофер”- Сюж/рольле уен уйнау барышында бер- берсенә игьтибарлы булуны арттыру,ачык,төгәл сөйләм булдыруга ирешү.<br>Дид\уен:”Тасманы урау.”<br>Максат:Озын ,кыска төшенчәсен ныгыту.Төсләрне дөрес аеру.Бармак хәрәкәтләрен ныгыту.<br>Материал:кызыл төстә озын һәм яшел төстә кыска тасмалар,2 таякчык.<br>(Румия,) | Балаларның сөйләм телләрен үстерү, сүзлек запасын баету, игътибарларын, хәтерләрен ныгыту йөзеннән өйрәнелгән тел шомарткычларны кабатлау. | Төрле озынлыктагы юллар төзергә, корылманы мөстәкыйль рәвештә киңлеккә,озынлыкка үзгәртергә өйрәтү; төсе,зурлыгы буенча предметларны туры китереп сайлый белү күнекмәләрен ныгытырга; өлкәннәр тормышына һәм хезмәтенә кызыксыну уяту. | Әти-әниләр белән әңгәмә. |

14 сентябрь  Сишәмбе

| Көндәлек режим | Күпкырлы белем бирү эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |
| **Иртән** | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Иртәнге гимнастика<br>Мнемоталицалар ярдәмендә гади җөмләләр төзеп хикәя төзергә өйрәтү.<br>Үстерешле уен:”Мин башлыйм ,син дәвам ит”-хәтерне ныгыту,логик фикерләүне үстерү.<br>Дид\уен:”Нинди фигура күрәсез ? “<br>Максат:Геометрик фигураларның исемен ныгыту.Төсләрне ныгыту.<br>Материал: түгәрәк,өчпочмак һәм квадрат. | Дид\уен”Күбәләкне үз чәчәгенә кундыр”.<br>Максат:Төсләрне ныгыту.Уйлау сәләтен үстерү.<br>Материал:кызыл ,сары һәм зәңгәр чәчәкләр шундый ук төстәге күбәләкләр. (Ислам,) | Агач конструкторларны тәкъдим итү.<br>-төп төзелеш кисәкләрен аера, таный, исемен атый белүне ныгыту(кубик, пластина, кирпеч, цилиндр). Яңа төзелешләр уйлап чыгару сәләтен үстерү. | Биек һәм тәбәнәк капкалар төзергә, төзелешләрне сүтеп, материалларны савытына җыеп куярга өйрәтү. | |
| **Белем бирү эшчәнлеге** | **Әвәләү** «Көзге агач».<br>• Төрле өлешләрен күрсәтеп, пропорцияләрен чамалап, агачны сурәтләргә өйрәтү.<br>• Әвәләп ясауның таныш ысулларын кулланып, балаларның предметларны әвәләп ясау күнекмәләрен ныгыту.<br>Балаларны туган як үсемлекләре белән таныштыруны дәвам итү.<br>**Физкультура**<br>Упражнять детей в ходьбе колонной по одному, беге врассыпную (повторить 2-3 раза в чередовании); упражнять в прокатывании мяча, лазанье под шнур . | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| **Прогулка** | Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш. | Саф һавада йөрү<br>Кошларны үз-үзләрен тотышларын күзәтү, аларны ашатырга кирәклеге турында аңлатү-(каргалар коймадан, агачларның калын ботакларында утырып күзәтәләр, чыпчыклар чыбыкта, күгәрчен түбәдә h.б)Кошларны зурлыклары буенча чагыштыру. | Индивидуаль эш<br>Кечкенә тупларны күрсәтелгән җиргә төбәп ыргыту.<br>Максат: предметларны ераклыкка ыргыту күнекмәсен ныгыту (Азалия,Ралина) | Уен.”Төсле Автобуслар”төсләрне, формаларны аера һәм чагыштыра белергә өйрәтү, автобуста<br>үз – үзеңне тота белү күнекмәләрен үстерү. | Хезмәт<br>балалар белән бергәләп кошларны ашату – кошларга карата кайгыртучанлык тэрбиялэу.<br><br>Урамга алып чыккан уенчыклар белэн балаларнын мостэкыйль уеннары. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Кич** | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Йокыдан соң гимнастика Массажлы коврикларда йөрү. Дид\уен::"Күрсәт ,тәгәрәт."<br>Максат:Балаларның уйлау сәләтләрен үстерү.Схемага карап геометрик фигураны тану.<br>Материал:тартма,туп,шар,алма,апельсин,мандарин,тәгәрмәч | Дид\уен"Дүртенчесе артык"<br>Максат: Балаларның сүзлек запасын киңәйтү, арттыру, игътибарлылыкны, логик фикерләү сәләтен, бәйләнешле сөйләмне үстерү. Чагыштырырга һәм нәтиҗә ясарга, предметларны төркемләргә өйрәтүне дәвам итү.<br>(,Ралина) | Уен- күнегү "Тәмле сүз". ( Туп белән.) ( Үрнәк: рәхмәт, зинһар өчен, исәнмесез, хәерле көн һ. б.) | Өй төзергә, өй тирәли коймалар урнаштырырга өйрәтү, төзелгән өй янында төрле- төрле йорт хайваннары, вак уенчыклар белән уеннар оештырырга күнектерү; төзелешне яхшылап сүтәргә һәм детальләрне төсе һәм төре буенча урыннарына урнаштырырга күнектерү. | Әти-әниләргә "Юл йөрү кагыйдәләре"дигән темага киңәшләр бирү.Өйләренә кайтканда ,бакчага килгәндә балаларга һәр вакытта юл йөрү кагыйдәләрен аңлатуларын сорау. |

15 сентябрь Чәршәмбе

| Көндәлек режим | Күпкырлы белем бирү Эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |
| **Иртән** | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>физик үсеш. | Балаларның аң үсешенә ирешүгә ярдәм итүче төрле дидактик уеннар: “Мозаиканы җыеп бетер”<br>“Дөрес итеп тез”<br>Балаларның кул чуклары күнегүләре аша сәламәтлекләрен ныгыту,психологик халәт тудыру;<br>уеннар аша логик фикерләү сәләтләрен үстерү;<br>уеннарга кызыксыну хисе тәрбияләү.<br>Дид\уен“Тылсымлы шарлар”<br>Максат: Төсләрне таный белергә өйрәтү. Предметларны бер-берсенә куеп карау юлы белән кирәкле төсне сайлап, туры китерергә өйрәтү. | Дид.уен: “Нәрсә артык”-балаларның кыргый һәм йорт хайваннары турында турында белемнәрен ныгыту.<br>“Йорт хайваннары һәм аларның балалары”<br>Балаларның йорт хайваннары турындагы белемләрен киңәйтү Бозау, бәрән, колын, кәҗә бәтие сүзләре хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру.<br>Тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгы формалаштыру. Игътибарны, хәтерне үстерү. Хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | Газиз,Ильнар, Мансурларны - уйнаганнан соң уенчыкларны урыннарына алып куярга кунектерү | Табигать почмагында хезмәт- голләргә су сибүдә катнашу-голләрне карау , тәрбияләү теләге уяту.<br>Төзелеш материаллары белән уеннар оештыру-конструкциялэу осталыкларын устеру. | Әти –әниләрне төркемдәге үзгәрешләр ,яңалыклар белән даими таныштырып тору ,сорауларга җавп бирү. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Белем бирү эшчәнлеге** | **ФЭМП Сан һәм предмет билгеләре арасындагы бәйләнешне ачыклау. Зур, кечкенә, иң кечкенә. Квадрат. Игъти- барлылык-ны камилләштерү**. Е.В.Колесникова. - 20 б.<br><br>**Музыка** музыка житэкчесе планы буенча | | | | |
| **Прогулка** | Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш. | Эт-мәчене күзәтү. Алар турында сөйләү .<br>Ни өчен йорт хайваннары дип атаганны аңлату.<br>Сүзлек өстендә эш: | Индивидуаль эш<br>Уен: “Минем янга йөгерегез”<br>Балаларны сигнал буенча бер – берсенә бәрелмичә йөгерергә өйрәтү.<br>Бер төркем балалар белән тел шомарткыч өйрәнү:<br>"Кара карга<br>кардан бара ,канатларын кага кага.” | Хәрәкәтле уеннар:<br>“Йөгереп җит һәм сикер”<br>Максат: дөрес сикерү алымнарын булдыру.<br>“Юл буйлап кем тизрәк йөгереп килеп җитә?”<br>Максат: пространствода ориентлашуны үстерүне дәвам итү. | Алып чыгылган материал белән ирекле уеннар<br>ФК буенча төп хәрәкәтләрне ныгыту. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Кич | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Йокыдан сон гимнастика, сулыш гимнастикасы,<br>массажлы коврикларда йору.<br>“Өч дунгыз баласы” әкиятенең рәсемнәрен карау – әкиятнең таныш өлешләрен рәсемнәргә карап сөйләргә өйрәтү, әкиятнең эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга җавап бирә белүне ныгыту. | “Уңайлы өй”<br>Төрле әйберләрне көндәлек тормышта кулланылышы буенча төркемнәргә берләштерергә һәм ул төркемнәрне гомумиләштерүче сүзләр белән әйтергә (савыт – саба, киемнәр, аяк киемнәре, җиһазлар, уенчыклар) өйрәтү. (Кәрим,) | Уен вакытында уенчыкларын бер-берсеннән тупас рәвештә тартып алмаска,төзегә н әйберне җимермәскә өйрәтү. | Сюжетлы-рольле уен”Кибеттә.”<br>-балаларны кибеттә үзләрен тоту кагыйдәләрен үтәргә, сатучыга ягымлы эндәшеп рәхмәт әйтеп китәргә кирәклеген аңлату. | Мәйданчы кта кардан корылмала р төзү |

16 сентябрь-Пәнҗешәмбе

| Көндәлек режим | Күпкырлы белем бирү эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Иртән** | Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш. | Иртәнге гимнастика.<br>Дид.\уен «Кирәкле төсне тап».-:<br>Балаларны төсләрне аера белергә өйрәтү, действовать по устной инструкции.<br>Ихтибарлыкларын арттыру..<br>Дид.\уен: “Төсен дөрес итеп әйт!”<br>Максат: Төсләрне аера белергә. Теге яки бу предмет, җисем һәм әйберләрнең төсен дөрес әйтә белүләренә ирешү. | “Төсле вагоннар”<br>Балаларны бер төстәге вагоннардан поезд төзергә өйрәтү. Яшелчә, җиләк-җимешләрне кирәкле төркемнәргә төркемләү.<br>Төсләрне формасын белүләрен, танып белүләрен ныгыту.<br>(ИсламИлнар) | Сабынны дөрес куллану, кулларны, битне чиста юу; юынгач коры итеп сөртенү, сөлгене урынына элүне формалаштыру.<br>Кем кулларын һәм битен<br>Сабын белән юмаган?<br>Ап-ак сөлге өстендә<br>Кап-кара таплар калган. | Өстәл уеннары оештыру-пазлы жыярга өйрәтү.<br>Мозаикалар белән уйнау-кул чуклары мускулларын ныгыту.<br>Тозелеш материаллары белән уеннар оештыру-конструкциял эу осталыклары н устеру. | Әти – энилэр елән баланың<br>үзен бакчада ничек тотуы турында сөйләшү,киңәшләр бирү.<br>. |
| **Белем бирү эшчәнле** | **Рәсем«Түтәлдәгечәчәкләр».**<br>• Кәгазь битенә рәсем ясарга (урнаштырырга), пумала (сабаклар, яфраклар, киртә) һәм бөгәрләнгән кәгазь белән (чәчәкләр) рәсем төшерүне аралаштырырга өйрәтү.<br>• Буяулар, пумала белән эшләү күнекмәләрен, туган як үсемлекләре турындагы белемнәрне ныгыту.<br>• Нәфасәти (эстетик) кабул итүне үстерү<br><br>**Физкультура**<br>Упражнять детей в ходьбе колонной по одному, беге врассыпную (повторить 2-3 раза в чередовании); упражнять в прокатывании мяча, лазанье под шнур . | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Прогулка** | Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш. | Яңгыр яуганны күзәтү.<br>Җил исүенә игътибар итү.<br>Көзге яңгыр.<br>-Апа,безгә артыбыздан<br>Шыбыр-шыбыр кем дәшә?<br>-Кем дә дәшми,көзге яңгыр<br>Зонтик белән сөйләшә.<br>*(Мәрзия Фәйзуллина*) | Индивидуаль эш Борҗаларнең берсеннән икенчесенә сикереп йөрү | Хәрәкәтле уеннар:»Мине куып тот»,»Миңа йөгереп кил”-балаларның хәрәкәт активлыгын арттыру.<br>“Түгәрәк уенын” уйнау .<br>Бир кулыңны, бир кулыңны,<br>Булсын әле түгәрәк.<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Булсын әле түгәрәк.<br>Күтәреп кулларыбызны<br>Чәп-чәп итеп кул чабыйк.<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Чәп-чәп итеп кул чабыйк.<br>Ягез хәзер берләшеп<br>Тыпырдап биеп алыйк.<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Тыпырдап биеп алыйк. | Таудан шуу.Балаларның бер-берсен чанада тартып уйнаулары. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Кич** | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Уен “Трамвай”. Трамвайның рельстан өйргәнен истә калдыру, бүлмәдә бер-бер артлы, бәрелмичә йөрү.<br>Табышмак “Сукмактан да чыгалмыйлар, бер-берсен дә уздырмыйлар /трамвай”/. | Дид.\уен:”Кайда ,нәрсә ?”<br>Максат:Әйләнә–тирәдә ориентлашу.Зур, кечкенә төшенчәсен һәм төсләрне ныгыту. | Ирекле әвәләү<br>Балаларның түгәрәксыман хәрәкәтләр белән уч төбендә әвәләү алымы белән әвәләүне ныгыту, әвәләүгә кызыксыну тәрбияләү, чиста эшләү күнекмәсен үстерү.<br>Пластилин, такта | Машиналар, коляскалар б/н уеннар-Уеннар вакытында балаларнын уз ара аралашулары на игътибар итү, балаларның торкемлэшул эрен хуплау | Ай дәвамында “3-4 яшьлек балаларның үсеш үзенчәлекләре”, “Үзсүзлелек һәм киреләнү” темаларына консультация |

17 сентябрь жомга

| Көндәлек режим | Күпкырлы белем бирү эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Иртән** | танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү<br>сәнгати үсеш<br>физик үсеш. | Иртәнге гимнастика<br>Балаларны янгын сүндерү машинасы белән таныштыру.<br>Янгын сүндерүчеләр эше турында элементар белемнәр формалаштыру, балаларны янгын сүндерү машинасы белән таныштыру, машинаның өлешләрен танырга һәм табырга өйрәтү, балаларның сөйләмен үстерү, сүзлекләрен янгын машинасы, су белән цистерна сүзләре белән баету.<br>Материал: "Яшәгән җир йөзендә фил баласы" — әкиятенә иллюстрация.уенчык фин баласы, уенчык янгын сүндерү машинасы, машианың катыргыдан киселгән детальләре (өлешләре). | Ирек белән дидактик уеннар уйнау: "Бер-күп", "Буяулар", "Минем формам ни нинди?"<br>Дид\уен: "Тылсымлы фигуралар"<br>Максат: Уйлау-фикерләү сәләтен үстерү. Рәсем ясау алымнарын ныгыту. | Өстәл янында үз-үзеңне дөрес тотуның иң гади күнекмәләрен формалаштыру: аш һәм чәй кашыкларын салфетканы дөрес куллану. Ашап туйгач рәхмәт белдерергә күнектерү<br>Утыр, балам, ашарга...<br>(Халык авыз иҗаты)<br>Утыр, балам, ашарга,<br>Түгеп-чәчеп ашама.<br>Матур утыр табында,<br>Алдыңа күл ясама.<br>Ипи валчыгыңны койма,<br>Аяк астына ташлама. | Төркем бүлмәсендә, мәйданчыкта тәртип һәм чисталык сакларга өйрәтү | «3 яшьлек балаларда мөстәкыйльлек һәм үз-үзеңә хезмәт күрсәтү»дигән темага күчмә папка булдыру. |
| **Белем бирү эшчәнлег** | **Сөйләм теле үстерү„ПЕСИ БАЛАЛАРЫ БЕЛӘН" ДИГӘН СЮЖЕТЛЫ КАРТИНА КАРАУ**<br><br>1) балаларның көзге үзгәрешләр турындагы белемнәрен ныгыту, сюжетлы картина персонажларын игътибар белән карау, эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү, иҗадилык элементларын күрсәтү осталыгын формалаштыру, песи һәи аның балалары исемнәрен сөйләмдә куллану, җәнлекләр гамәлен билгеләүче сүзләр хисабына сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, сенсор сәләтләрен, уен кагыйдәләрен үтәү теләген үстерү;<br>3) песиләргә карата сакчыл мөнәсәбәт, кайгыртучанлык тәрбияләү.<br><br>**Сары,кызыл яфраклар**<br>1)балаларда көз,кыш ел фасылларының характерлы билгеләре белән таныштыру;бер ел фасылы икенчесен алмаштыруы турында мәгълумат бирү; көәге явраклар турындагы белемнәрен (яфракларның төсләре узгәрә, алар коелалар) киңәйтү. Авазлар әйтелешен | | | | | |

<table>
<tr><td></td><td colspan="5">ныгыту. 2)балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен,бәйләнешле сөйләмен үстерү;көзге табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәтү;<br>3)балаларда чиста, пөхтә эшләүтеләге тәрбияләү.<br>Саф һавада физкул\ра<br>Упражнять детей в ходьбе колонной по одному, беге врассыпную (повторить 2-3 раза в чередовании); упражнять в прокатывании мяча, лазанье под шнур .</td></tr>
<tr><td>Прогулка</td><td>Танып белү<br>Сөйләм теле үсеше.<br>Физик үсеш.</td><td>Мәйданчыктагы агачларга кунган кошларны күзәтү, исемнәрен әйтү; гөр-гөр, чырык-чырык, кар-<br>кар аваз ияртем нәрен ачык әйтергә күнектерү;<br>томшык, сикерә, гөрлиләр, җим, чүплиләр, чырылдый, җитез, өлгер сүзләре хисабына сүзлекне баету;<br>балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген,<br>сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>кошлар турында кайгырту, аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү.</td><td>Индивидуаль эш:<br>"Хәрәкәтле уен:<br>" Кем тубны еракка-рак ата?"<br>Бур-р: уенда чиратлашып кар тубын атырга өйрәтү.<br>«Флаг янына йөгер».<br>Бурыч.: сигнал буенча хәрәкәтләнә белүне</td><td>Хезмәт<br>балалар белән бергәләп юлларны кардан чистарту -ярдәм итү теләге уяту һәм бергәләшеп эшләргә өйрәтү.</td><td>Көрәкләр, совоклар, себеркеләр формачкалар, кызыл, зәңгәр флаглар.<br>Таудан шуу.</td></tr>
</table>

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Кич** | социаль-коммуникатив үсеш<br>танып белү үсеше<br>сөйләм үстерү | Йокыдан соң гимнастика<br>Массажлы коврикларда йөрү.<br>Дид\уен:“Тылсымлы торба”<br>Балаларга уенчыкларны тикшererергә һәм аерым өлешләрен билгеләргә өйрәтү. Балаларның игътибарын үстерү, сүзлеген баету, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү. Бармаклар эшчәнлеген нығыту. | Дид\уен:“Нәрсә ничек кычкыра?<br>Балаларга хайваннарны тышкы кыяфәтләре һәм аваз иярtemнәре буенча таный белергә өйрәтү. Балаларның ишетү сәләтен үстерү. Хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | Уенчык һәм башка әйберләрне саклап тотарга ,алардан урынлы фадаланырга өйрәтү.<br>Уенчыкларың чирләсә<br>Үз кулыңнан килмәсә<br>Миңа китер туп-туры<br>Мин аларның –докторы. | С/р уен «Автобус» - балаларны 2-3 кешедән (шофер-пассажир)торган сюжетларда узара бердәм эш итәргә өйрәтү. | *«Балалар бакчасында режим моментлары һәм көндәлек режимны оештыру»* дигән консультация уздыру. |

20 сентябрь Дүшәмбе

| Көндәлек режим | Күпкырлы Белем бирү эшчәнлеге | Белем бирү өлкәсендә балалар һәм зурлар эшчәнлеге | | | Мөстәкыйль эшчәнлек өчен үстерешле мохит булдыру | Әти-әниләр белән эш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Төркем һәм төркемчә | Шәхес белән эш | Режим вакытында белем бирү эшчәнлеге | | |

<table>
<tr>
<td>Иртән</td>
